ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2024 с.Старое Дрожжаное № 200.

Түбән Чәке авылы Мәдәният йортына Ильясов Рафаэль Зариф улы исемен бирү турында

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты Ильясов Рафаэль Зариф улы истәлеген мәңгеләштерү максатларында «Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2017 елның 31 гыйнварындагы 14/2 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы күренекле граждannар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турында материалларны карау буенча комиссия утырышының 2024 елның 25 апрелендәге беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Җирлекара мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең 15 нче филиалы - Түбән Чәке авылы Мәдәният йортына - ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты Ильясов Рафаэль Зариф улы исемен бирергә.

2. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Җирлекара мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе директорына (Р.Д. Шәрәфетдинов) Түбән Чәке авыл мәдәният йорты хезмәткәрләренең хезмәт кенәгәләренә учреждениенең исемен үзгәртү турында язма кертергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов